КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 август г.Казань № 785

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 10 ноябрь, 1060 нчы карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәп-кәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 октябрь, 1060 нчы карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Министрлык сайлап алу үткәрелгән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе

бюджет системасының бердәм порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 23 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 10 пункты һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен хосусый мәгариф оешмалары, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә хосусый мәгариф оешмаларына, индивидуаль эшкуарларга таләпләр;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 12 пункты нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 13 - 15 пунктлары нигезендә заявкаларны карау кагыйдәләре;

хосусый мәгариф оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә сайлап алу үткәрү турында игълан нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый тәкъдим итүнең башлану һәм тәмамлану вакыты;

сайлап алуда җиңүчеләр тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчеләрне килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Вәкаләтле органның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алу җиңүчене билгеләү көненнән соң килүче 14 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.

Министрлык сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән соңгы бишенче календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүматны урнаштыра:

гаризаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм үткәрү урыны;

гаризалары каралган хосусый мәгариф оешмалары, шәхси эшмәкәрләр турында мәгълүмат;

гаризалары кире кагылган хосусый мәгариф оешмалары, шәхси эшмәкәрләр турында мәгълүмат, аларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризалар

туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында игъланнар нигезләмәләре күрсәтеп;

килешү төзелә торган субсидия алучыларның исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидияләрнең күләме.»;

16 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәләренә» сүзен «нәтиҗәләре мәгънәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «максатлар,» сүзен төшереп калдырырга;

28 пунктта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәнең мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга;

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $29^1$ пункт өстәргә:

«$29^1$. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактлары чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

32 пунктта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга.

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәп-кәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 октябрь, 1060 нчы карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 10 пунктының дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы утыз беренче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин